**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе турында» 2004 елның 27 мартындагы ПУ-290 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы, 2012 елның 4 июнендәге ПУ-416 номерлы, 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1091 номерлы, 2020 елның 16 апрелендәге ПУ-231 номерлы указлары, Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 3 июлендәге 461 номерлы һәм 2024 елның 11 июнендәге 439 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт бүләкләре комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Р.Н. Мөхәммәдиевны, А.М. Фроловны чыгарырга;

б) Комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Глазков Андрей Александровичны – В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең персонал белән эшләү идарәсе башлыгын (килешү буенча);

Шәйдуллин Дамир Фәрит улын – Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасарын.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 14 октябрь
№ 798